*TÜRÜK*
*Uluslararası Dil, Edebiyat*
*ve Halkbilimi Araştırmaları Dergisi*
*2015 Yıl:3, Sayı:6*
*Sayfa:64-70* *ISSN: 2147-8872*

# KREŞİN TATARLARI AĞIZLARINDA TÜRKÇE ASILLI VE ALINTI KELİMELER

Zoya Kirillova*

**ÖZET**

Çalışmamız, İdil ve Ural Tatarlarının etnokonfessional (Etnik mezhep) grubunu teşkil eden Kreşin (Hristiyan) Tatarlarının ağızlarındaki Türçe asıllı ve alıntı kelimelerin incelenmesinden oluşmaktadır.

Kreşin Tatarlarının çoğunluğu Tataristan Özerk Cumhuriyeti'nde yaşamaktadır, aynı şekilde Kreşin Tatarlarının farklı grupları komşu Başkurdistan, Udmurtiya Cumhuriyetleri, Çilebi, Kirov ve Samara bölgelerinde de yer almaktadır. Bu şekilde çeşitli bölgelere dağılarak yaşayan Kreşin Tatarları dil özellikleri bakımından da, örf-adetleri bakımından da birbirlerinden oldukça farklıdırlar. Kreşin Tatarlarının büyük bir kısmı İslam dininden Hristiyanlığa geçen Tatarlardan oluşurken geriye kalan kısmı ise Tatarlaşmış Fin-Ugor halklarından ve yine Türk kökenli halklar arasına giren Çuvaşlardan oluşmaktadır ya da bu hakların güçlü etkisi altında kalmışlardır. Bu fikir, Kreşin Tatar ağızlarının dil özellikleri ile de ispatlanmaktadır.

Kreşin Tatarlarının her ağzında Türkçe asıllı kelimeler çoğunluğu oluşturmaktadır. Şunu da belirtmek gerekir ki; belirli ölçülerde Müslüman Tatarlardan farklılık gösteren ve yaşamlarından kaynaklı olarak Kreşin (Hristiyan) Tatarlarının ağızlarında Tatar edebî dili ile ortak olan kelimeler dışında yazılı eserlerde yer alan ve günümüz Türk lehçelerinin bazılarında kullanılmakta olan kelimeler de korunmuştur. Çalışmamızda bu kelimeler üzerine de incelemeler yapılmıştır.

Kreşin Tatar ağızlarında diğer dillerden giren kelimelerden Arapça, Farsça ve Rusça alıntılar büyük çoğunluğu teşkil etmektedir. Bu alıntıların, alıcı dille karşılaştırıldığında ne gibi ses değişimleri geçirdiği, Tatar Türkçesinin diğer ağızlarıyla farklılaşan kullanım özellikleri de incelenmiştir.

* Doç. Dr., Kazan (İdil Boyu) Federal Üniversitesi, Filoloji ve Kültürler Arası Etkileşimler Enstitüsü, Öğretim Üyesi, zkirillova@yandex.ru

Kreşin Tatarlarının farklı grupları, yaşadıkları yerlere göre komşu Çuvaş, Udmurt ve Mari dillerinden de alıntılar kabul etmiştir. Çalışmamızda bunlara da yer verilmiştir.

İncelemeler sonuçlanana kadar Tatar halkının kendine has özellikleri olan bir grubu olarak kabul edilen Kreşin Tatarlarının ağızlarının temelini Türkçe sözler teşkil etmektedir. Tüm ağızlarda da ses değişimlerine uğrayan Rusça, Arapça ve Farsça alıntılar kullanılır, farklı yerleşim birimlerinde ise komşu halklarla ilişkiler temelinde, Çuvaça ve Udmurtça kelimeler de yer alır.

**Anahtar kelimeler:** Kreşin (Hristiyan) Tatarları, ağızlar, Türkçe asıllı kelimeler, alıntılar.

## WORDS WITH TURKIC ORIGIN AND LOANWORDS IN SPEECH KRYASHEN (CHRISTIAN) TATARS

### ABSTRACT

Our works is based on study of loanwords and words with Turkic origin in speech of Kryashen – Christian Tatar, who is relate to Volga and Ural ethnic-denominational group of Tatars.

Most of Christian Tatar live in republic of Tatarstan as well as some of them settle down in neighboring republics of Bashkortostan, Udmurtia; Chelyabinsk, Kirov and Samara regions. Being scattered in different areas, Kryashens have significant disparities both in the language features and in the customs and traditions.

The main group of Christian Tatars are ones who has changed Islam to Christianity. The others are descendants of an impact by Tatar Finno-Ugric folk or have an origin from Chuvash people who are also the part of Turkic nation or influenced by them. This opinion is proved via a linguistic feature of Christian Tatar dialects.

In each dialect of Christian Tatars loanwords related to Turkic origin are in the main position. It is important to mention: living aside of Muslim Tatars, besides Christian Tatars dialects, their own literary language, there are some words, which are kept in written manuscripts and still used in a spoken language. In our study we analyze these words.

Among borrowings, Persian, Arabic and Russian loanwords take a majority in the speech of Christian Tatars. In our study we examine these loanwords in the background of the sound changing and trace the peculiarities of the Christian Tatars language in comparison with other speech of the Tatar language. According to habitation, some groups of Christian Tatars accepted loanwords of the Chuvash and Udmurt languages. They have been mentioned in our work.

Due to the study Turkish words make the basis of speech of Christian Tatars, who are considered as unique group of Tatar nation. Russian, Arabian and Persian loanwords, phoning to sound changes, are used in all languages, but in individual parochialism. Having connection and communicated with the neighbor nations, some Chuvash and Udmurt words were borrowed.

**Keywords:** Kryashen (Christian) Tatars, speech, words with Turkic origin, loanwords.

## КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫ СӨЙЛӘШЛӘРЕНДӘ ТӨРКИ НИГЕЗЛЕ ҺӘМ АЛЫНМА СҮЗЛӘР

Хезмәтебез Идел һәм Урал татарларының этноконфессиональ төркемен тәшкил итүче керәшен сөйләшләрендәге төрки нигезле һәм алынма сүзләрне тикшерүгә багышлана.

Керәшеннәрнең күпчелеге Татарстан республикасында яши, шулай ук аерым төркемнәре күрше Башкортостан, Удмуртия республикаларында, Чиләбе, Киров һәм Самара өлкәләрендә дә урнашкан. Шундый төрле территориягә таралып яшәүче керәшеннәр тел үзенчәлекләре ягыннан да, гореф-гадәтләре буенча да бер-берсеннән бик нык аерылып тора.

Керәшеннәрнең төп өлеше ислам диненнән христианлыкка күчкән татарларны тәшкил итә, ә калганнары исә татарлашкан фин-угыр халыкларыннан һәм төрки халыкка кертелгән чуашлардан килеп чыккан яисә бу халыкларның көчле йогынтысын кичергән [Kirillova 2015: 727]. Әлеге фикер керәшен сөйләшләренең тел үзенчәлекләре белән дә дәлилләнә.

Керәшен татарларының һәр сөйләшендә дә төрки нигезле сүзләр төп урынны алып тора. Шунысын да билгеләп үтү мөһим: мөселман татарларыннан күпмедер дәрәҗәдә аерымланып яшәгәнлектән, керәшен сөйләшләрендә, татар әдәби теле белән тәңгәл килгән сүзләрдән тыш, язма истәлекләрдә урын алган һәм хәзерге төрки телләрнең кайберсендә кулланыла торган сүзләр дә сакланып калган. Шундый берничә сүзгә күзәтү ясыйк.

**Аргыш** – туй башлыгы [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге 2009: 50], туйда иң дәрәҗәле кеше. Керәшен йолаларын бик яхшы белгән аргыш туйга үз исеменнән зур итеп һәм матурлап әзерләнгән чәкчәк яки бавырсак алып бара. Аргыш сүзе татар әдәби телендә кулланылмый, бары Пермь татарлары сөйләшендә туйга парлап килгән туй башлыкларын аңлата, ә Себер татарларында “йөк күчерү урыны” мәгънәсен бирә. Башка төрки халыкларда исә бу сүз актив урын ала. Мәсәлән, алтай, якут, хакас, ойрот телләрендә аргыш – “иптәш, дус, юлдаш” мәгънәсендә кулланыла; башкорт сөйләшләрендә – киртәнең бер торыгы (“юлның бер өлеше” мәгънәсеннән); гагауз

телендә аркуш – “кылкубыз (скрипка) сызгычы” (арлы-бирле йөрүеннән) дип аңлатыла [Әхмәтьянов 2015: 102].

**Ардаклы** сүзе керәшен сөйләшләрендә – “хөрмәтле, кадерле”, **ардаклау** исә ике мәгънәне белдерә: 1) хөрмәтләү, кадерләү, саклау; 2) аралау, чүптән арындыру, чистарту [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге 2009: 50-51]. Бу сүзләр татар теленең Пермь, Эчкен, Златоуст, Касыйм татарлары сөйләшләрендә һәм мишәр диалектында “хөрмәтле” һәм “хөрмәтләү” мәгънәләрендә кулланыла. Ардак һәм ардаклау сүзләре башка төрки телләрдән уйгыр, кыргыз, каракалпак телләрендә дә “хөрмәтләү, олылау, кайгырту” мәгънәләрен бирә [Баязитова 1997: 88].

Керәшен татарларының барлык сөйләшләрендә дә, “кисү” мәгънәсен белдерү өчен, **пычу / печү** сүзләре дә кулланыла [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге 2009: 529, 550]. Мәсәлән, *күлмәк печү, утын пычу* һ.б. Әлеге борынгы төрки сүз мишәр һәм Себер татарлары диалектларында да сакланып калган. Татар әдәби телендә исә печү сүзе “кастрация, кысырлату” мәгънәсендә генә кулланыла [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге 2005: 415]. Пыч- тамырыннан татар әдәби телендә пычак, пычкы, почмак сүзләре ясалган. Керәшен сөйләшләрендә, болардан тыш, почкак сүзе дә кулланыла, ул кисәннән калган әйбер, кечкенә кыйпылчык мәгънәсен белдерә. Башка төрки телләрдә дә пыч- тамыры төрле фонетик вариантларда гаять киң таралган: бес- (башкорт), пач- (чуаш), быс- (якут), быш- (тува), пиш- / биш- (нугай, казак, каракалпак), бич- (кыргыз, угыз, комык, кырым татар, карачай) һ.б. [Баязитова 1997: 89]. Билгеле булганча, төрек әдәби телендә һәм диалектларында да бу сүз “кисү” мәгънәсендә кулланыла: odun biç-, ağaç biç-, kumaş biç- һ.б., шул фигыльдән bıçak сүзе дә ясалган.

**Күз** сүзенең “утлы күмер, ут” мәгънәсе хәзерге татар әдәби телендә кулланылмый, бары ут-күз парлы сүзендә генә сакланып калган. Мәсәлән: *Ут-күздән Алла сакласын. Ут-күз чыга күрмәсен.* Керәшен сөйләшләре урынчылыкларында, шулай ук урта һәм Себер татарлары диалектларының кайбер сөйләшләрендә күз, күзле сүзләре “утлы күмер, ут” мәгънәсендә еш кулланыла. Башка төрки телләрдә дә ул бик актив: төрекмән телендә – көөз, төрекчә – köz, хакас, тува, алтай телләрендә – köc һ.б. Рифкать Әхмәтьянов фикеренчә, әлеге мәгънәдәге күз сүзе куз / коздан палатальләшеп, ягъни нечкәреп ясалган [Әхмәтьянов 2015: 485].

**Арыу / ару** борынгы төрки сүзе М. Кашгари сүзлегендә һәм әрмән-кыпчак текстларында “изге, гөнаһсыз” мәгънәләрендә кулланылган [Баязитова 1997: 88]. Хәзерге керәшен сөйләшләрендә дә ул “Арыу кыз Мария”, “аруландыру” (изгеләндерү) рәвешендә еш урын ала. Дини булмаган контекстта исә бу сүз “яхшы, чиста” мәгънәләрен аңлата һәм шулай ук арулау (чистарту) фигылен дә ясый. Моннан тыш, керәшен татарларында “арыумысыз? / арумысыз?” исәнләшү, хәл-әхвәл сорашу сүзе булып тора һәм аңа “арыу / ару гына әле, арыубыз / арубыз” кебек җаваплар бирелә. Хәзерге төрки телләрнең күбесендә ару / арыу, әрү / әреү һ.б. “матур, затлы; саф, чиста” мәгънәләрен белдерә.

Башка теллəрдəн кергəн сүзлəрдəн исə керəшен сөйлəшлəрендə рус һəм гарəп-фарсы алынмалары зур күпчелекне тəшкил итə. Рус дəүлəте белəн уртак сəяси һəм икътисади тормыш нəтиҗəсендə, бигрəк тə рус алынмалары күплəп кабул ителгəн. Татар əдəби телендə һəм диалектларындагы кебек үк, керəшен сөйлəшлəрендə дə элегрəк үзлəштерелгəн рус сүзлəре бик нык үзгəртелгəн һəм татар теле закончалыкларына буйсындырылган. Мəсəлəн: рожь – арыш, соха – сука, мох – мүк, бревно – бүрəнə, солома – салам, озимые – уҗым, решётка – эрəшəткə, скирда – эскерт, капуста – кəбестə, творог – тугарук, варенье – баринҗа, печенье – пичинҗə, насилу – начылый, шарф – шарып, племя – пелəмə һ.б. Күренгəнчə, рус сүзлəрен үзлəштергəндə, сүз башына яки уртасына сузык аваз өстəү яки, киресенчə, сүз ахырындагы сузык авазны төшереп калдыру, калын сузыкларны нечкəгə əйлəндерү хас, тартык авазлар өлкəсендə исə х~к, ф~п, ж~ш, з~җ һ.б. тəңгəллеклəр урын ала.

Керəшен татарлары сөйлəшлəрендə христиан дине йолаларына караган алынма сүзлəр дə шактый зур урын били. Мəсəлəн: рождество – раштуа / раштыва, пасха – паскы, петров день – питырау / питрау (Петр көне, 12 июль), ильин (день) – элҗин (көн) (Илья көне, 2 август), поп – пуп, поминки – пуминка, венчать – минчəт (чиркəүдə никахлашу) һ.б.

Керəшен сөйлəшлəрендə рус алынмаларын кулланунын тагын бер үзенчəлеге кеше исемнəрендə ачык күренə. Рус исемнəре сөйлəмдə татар теленең əйтелешенə җайлаштырыла һəм төрле фонетик үзгəрешлəргə дучар була. Мəсəлəн: Катя – Кəтүк, Павел – Пауал, Николай – Микулай, Максим – Мəкчем, Пелагея – Палук, Осип – Учып, Оля – Үлүн һ.б. Гомумəн, керəшеннəрдəге кеше исемнəренең күбесе берничə вариантта кулланыла, -кай/-кəй, -ка/-кə, -кый/-ки, -ый/-и, -ай/-əй, -уш/-үш, -ук/-үк кебек кушымчалар исəбенə аларның саны арта. Мəсəлəн: Евдокия – Əүдеки, Аудыкай, Аудый, Аудатья, Аудук; Михаил – Микайла, Микуш, Микай, Микəй; Наталья – Наталҗа, Натай, Натка, Натуш, Натуша һ.б.

Күренгəнчə, кеше исемнəрендəге үзгəрешлəр сузык авазларга да, тартыкларга да карый. Керəшен сөйлəшлəрендə кеше исемнəрен кыскартып һəм төрле кушымчалар ялгап əйтү күренеше татар теленең башка сөйлəшлəре, мəсəлəн, Нократ, Пермь татарлары, мишəр диалекты һəм Себер татарлары сөйлəшлəре белəн дə уртак. Шулай ук башка төрки теллəрдə дə андый үзенчəлеклəр табыла. Галимнəр керəшен татарлары исемнəрен типологик яктан болгар-татар исемнəре белəн бик охшаш дип табалар [Баязитова 1997: 86].

Керəшен сөйлəшлəрендə кулланылган алынма сүзлəрнең алдагы төркеме – гарəп һəм фарсы теллəреннəн кергəн сүзлəр. Татар əдəби теле һəм башка сөйлəшлəре белəн чагыштырганда, аларның саны артык күп түгел. Гарəп һəм фарсы алынмаларын берлəштереп, түбəндəге тематик төркемчəлəрдə бирергə мөмкин:

1) дини эчтəлекле сүзлəр: Алла, Ходай – Кодай, дин / ден, иман (iman), оҗмах – җомак, фəрештə – пирештə, пəйгамбəр – пигəмбəр, кəбен (дини йола буенча өйлəнешү) һ.б.;

2) иҗтимагый тормыш, фән һәм мәгариф белән бәйле сүзләр: халык – калык, хөкүмәт – хыкумат / кыхумат, хәреф – кәреп, кәгазь – кагаз һ.б.;
3) көнкүреш әйберләре атамалары: сәгать – сәәт / сагат, ризык – ыризык, пәрдә, тастымал, чалбар – шалбар / чалбар һ.б.;
4) абстракт мәгънәле төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: вакыт – багыт, гомер – гүмер / гумер, дөнья – дөнҗа, һава – ауа, җәфа – җапа, һуш – уш, талигалы һ.б.

Мисал итеп китерелгән соңгы сүз – талигалы – татар әдәби телендә искергән сүз булып санала [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге 2005: 511], керәшен сөйләшләрендә “бәхетле” мәгънәсен белдерә һәм күбрәк балаларга карата теләк әйтү вакытында кулланыла, мәсәлән: *талигалы-тәүфиклы булсын!*

Керәшен татарларының аерым төркемнәре, яшәү урыннарына карап, күрше чуаш һәм удмурт телләреннән дә алынмалар кабул иткән. Андый сүзләрнең саны күп түгел һәм бары тик әлеге милләт вәкилләреннән килеп чыккан яки алар белән аралашып яшәгән керәшеннәр сөйләмендә генә урын ала. Мисал өчен, чуаш теленнән кергән алынмалар Тау ягы яки Мәлки керәшеннәрендә, ягъни Татарстанның Чуашстан белән чиктәш булган районнарында күзәтелә: тунди кен – дүшәмбе, утлари кен – сишәмбе, кәкәй – ит, кукша – пеләш, кырсут – йорт иясе, җекрәс – игез, чапле – яхшы, матур һ.б. [Баязитова 1997: 84-85]. Мәлки керәшеннәренең кием-салымнары һәм бизәнү әйберләре чуашларныкы белән охшаш, әмма аларның атамалары төрки нигезле дип санала: такыя, тастар, тастар яулыгы, ак калфак, кашпау һ.б.

Казан арты керәшеннәренең удмуртлар белән катнаш булган авылларында удмурт сүзләре кулланыла: кечтун көн – үлгән кешене искә алу көне (удмурт телендә – кисьтон корон), пучы – тал, агач бөресе, шуннан пучы бәйрәме исеме килеп чыккан, бужы чабу – нардуган чабу һ.б. [Баязитова 1997: 84]. Бу төбәктәге керәшеннәр бүгенге көнгә кадәр борынгы кием-салымнарының тулы комплексын саклаганнар (сүрәкә, түгәрәк яулык, укалы җилән, чукол (баш яулыгы), түшлек, чигәчә, маңгай тәңкәсе, муйтомар (хәситә) һ.б.) [Мөхәмәдова 2005: 23-24]. Аларның киемнәре һәм бизәнү әйберләренең көньяк удмуртларныкы белән охшашлыгы, уртаклыгы нык сизелә [Белицер 1951: 77-78].

Йомгаклап әйткәндә, татар халкының үзенчәлекле төркеме булып саналган керәшеннәр сөйләменең нигезен төрки сүзләр тәшкил итә, барлык сөйләшләрдә дә аваз үзгәрешләренә дучар ителгән рус, гарәп һәм фарсы алынмалары кулланыла, аерым урынчылыкларда исә, күрше халыклар белән бәйләнеш нигезендә, чуаш һәм удмурт сүзләре дә урын ала.

## ӘДӘБИЯТ

Әхмәтьянов, Рифгать 2015. *Татар теленең этимологик сүзлеге, I том (А-Л).* Казан: Мәгариф – Вакыт.

Баязитова, Флера 1997. *Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты.* Казан: Матбугат йорты.

Белицер, Вера 1951. *Народная одежда удмуртов.* Москва: Издательство Академии наук СССР.

Kirillova, Zoya 2015. *Kreşin Tatarlarının etnik kökenleri // 7. Uluslararasi Dünya Dili Türkçe Sempozyumu bildirileri /Fırat Üniversitesi (Elazığ, 16-18 Ekim, 2014). I. Cilt.* Elazığ: Fırat Üniversitesi Basımevi.

Мөхәмәдова, Рәмзия 2005. *Керәшен татарлары киеме.* Казан: Сүз.

*Татар теленең аңлатмалы сүзлеге* 2005. Казан: Матбугат йорты.

*Татар теленең зур диалектологик сүзлеге* 2009. Казан: Татарстан китап нәшрияты.